МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.06.2015 Казан ш. № 300

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге УП-542 номерлы Указына ярашлы рәвештә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әлеге боерыкка теркәлгән Исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Кадрлар бүлегенә:

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

өч көн вакыт эчендә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәргә;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә өч көн вакыт эчендә раслауга кертергә, ә алга таба, үзгәрешләр кертелгән очракта, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна вакыт эчендә төгәлләштерелгән Исемлекне әзерләп тапшырырга.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
24.06.2015 №300

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары**

**Исемлеге**

1. Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры;
2. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары.